СОВЕТ
СРЕДНЕТИГАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ
УРТА ТИГӘНӘЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** | **КАРАР**

27.05.2024 | с. Урта Тигәнәле | № 55

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Урта Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Алексеевск муниципаль районының Урта Тигәнәле авыл җирлеге Советы карары проекты турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Уставының XVI бүлегенә ярашлы рәвештә, Алексеевск муниципаль районының Урта Тигәнәле авыл җирлеге Советы

**карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Урта Тигәнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Совет карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Урта Тигәнәле авыл җирлеге »муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге Советы Карары проектын (алга таба – Карар проекты) 2 нче кушымта нигезендә беренче укылышта кабул итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүм порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Алексеевск муниципаль районының рә сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru) һәм гражданнар күпләп җыела торга урыннарда мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга:

- ТР Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге Башкарма комитетының административ бинасы: Урта Тигәнәле авылы, Яшел урамы, 13 йорт;
- Урта Тигәнәле авылы, Яшел урамы, 13 йорт адресы буенча мәгълүмат стенды;
- ТР Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге Урта Тигәнәле авыл мәдәният йорты бинасы: Урта Тигәнәле авылы, Яшел урамы, 12 йорт.

4. Карар проектына килгән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә :

1) Камалова Э.М. – 4 нче Урта Тигәнәле сайлау округы буенча депутат, төркем җитәкчесе;

2)Сибатова Д.С. – 7 нче Урта Тигәнәле сайлау округы буенча депутат, төркем әгъзасы;

3) Буранова Ф.Г. – 5 нче Урта Тигәнәле сайлау округы буенча депутат, төркем әгъзасы.

5. Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге Советы депутатларының карар проектына тәкъдимнәре төзәтмәләр рәвешендә комиссиягә 2024 елның 25 июненә кадәр кертелә.

6. Карар проектына гражданнарның тәкъдимнәре комиссиягә язма рәвештә Ф.И. А., туган елы, авторның адресы күрсәтелеп, ТР, Алексеевск районы, Урта Тигәнәле авылы, Яшел урамы, 13 йорт адресы буенча җибәрелә.

7. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Урта Тигәнәле авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Совет карары проекты буенча 2024 елның 26 июнендә 10-00 сәгатьтә гавами тыңлаулар билгеләргә. адресы: ТР, Алексеевск районы, Урта Тигәнәле авылы, Яшел урамы, 13 йорт

Гавами тыңлаулар Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге Советының 15.11.2006 ел №11 карары белән расланган Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибенә ярашлы рәвештә үткәрелә.

8. Комиссиягә җирлек Советы депутатларының төзәтмәләрен һәм гражданнарның карар проектына тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, аларны эшләп бетерергә һәм 2024 елның 01 июленә кадәр җирлек Советы каравына кертергә.

9. Әлеге карар, әгәр федераль законда башкасы каралмаган булса, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясының 8 өлеше нигезендә үз көченә керә.

10. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Урта Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **И.К.Хәмәтвәлиев**

Урта Тигәнәле авыл җирлеге
Советының
27.05.2024 ел,№ 55
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы « Урта Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында » Совет карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының « Урта Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Совет карары проектына тәкъдимнәр Урта Тигәнәле авыл җирлеге советына түбәндәге адрес буенча кертелә: ТР, Алексеевск районы, Урта Тигәнәле авылы, Яшел урамы, 13 йорт адресы буенча язма рәвештә төзәтмәләр таблицасы рәвешендә:

| № | Пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмә тексты | Төзәтмә исәпкә алынган проект тексты | Төзәтмә авторы поправки (Ф.И.А., адресы, уку ,эш урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, гавами тыңлаулары уздыруга 7 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә.
2. Гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризалар ТР, Алексеевск районы, Урта Тигәнәле авылы, Яшел урамы, 13 йорт адресы буенча язма рәвештә яки почта аша бирелә.
Гаризалар эш көннәрендә 8.00 дән 17.00 гә кадәр кабул ителә
3. Гражданнарның тәкъдимнәре эшче төркем тарафыннан теркәлә һәм карау өчен Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Урта Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советына һәм Башлыгына тапшырыла.

**Урта Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе** **И.К.Хәмәтвәлиев**

Урта Тигәнәле авыл җирлеге
Советының
27.05.2024 ел,№ 55
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Урта Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

**1. 7 статьяның 1 өлешендәге 12 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"12) балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;";

**2. 15 статьяның 3 өлешендә** «Җирлекнең сайлау комиссиясе тарафыннан яки» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

**3. 16 статьяның 8 өлешендә** «Сайлау комиссиясе тарафыннан», «Сайлау комиссиясен» сүзләре төшереп калдырырга

**4.24 статьяда:**
**-2 нче өлешне** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"2. Авыл җирлеге старостасы, аның составына әлеге авыл җирлеге керә торган авыл җирлеге Советы тарафыннан авыл җирлеге гражданнары җыены тәкъдиме буенча билгеләнә. Авыл җирлеге старостасы әлеге авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәм актив сайлау хокукына ия булган Россия Федерациясе гражданнары яки гражданнар җыены тәкъдим иткән көнне 18 яшькә җиткән һәм әлеге авыл торак пункты территориясендә урнашкан торак бинасы булган Россия Федерациясе гражданнары арасыннан билгеләнә.";
**- 3 нче өлеш** "муниципаль вазыйфаны" сүзләреннән соң "үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты муниципаль вазыйфасыннан тыш,"; сүзләре белән тулыландырырга;
**- 4 нче өлешнең 1 нче пункты** "муниципаль вазыйфаны" дигән сүзләрдән соң"үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты муниципаль вазыйфасыннан тыш," сүзләре белән тулыландырырга;

**5.25 статьяда:**
**-5 нче пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Гавами тыңлауларны үткәрү турында карар, аларны үткәрү вакытын һәм урынын күрсәтеп, һәм гавами тыңлауларга чыгарыла торган тиешле муниципаль норматив хокукый акт проекты, гавами тыңлауларын үткәрү көненә кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча, бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә), шул исәптән «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиеш.»;

**-6 нчы пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «6. Гавами тыңлаулар үткәрү турында карар һәм муниципаль норматив хокукый акт проекты басылып чыккан көннән(халыкка җиткерелгәннән) башлап район халкы җирлек Башлыгына гавами тыңлауларга чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт мәсьәләсе яки проекты буенча, шул исәптән «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы»федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша, тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрергә хокуклы. Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр юнәлеше гавами тыңлаулар уздырылганчы 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана. Җирлек Башлыгы килгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерүне һәм аларны җәмәгать тыңлауларында катнашучыларга җиткерүне оештыра.»;

**-9 нчы** пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре, шул исәптән кабул ителгән карарларның мотивацияле нигезләмәсе, «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында гавами тыңлаулар уздырылганнан соң 5 көннән дә соңга калмыйча бастырылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.»;

**6.35 статьяда:**

**- 6 өлешнең 2 пунктында б) пунктчасында** «Татарстан Республикасы Президентын » сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;

**- 6 өлешнең 3 пунктындагы а) пунктчасында** «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратына» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

**- 6 өлешнең 3 пунктындагы б) пунктчасында** «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

**- 8 нче өлешнең беренче абзацында** «Татарстан Республикасы Президентын » сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;

**- 8 нче өлешнең икенче абзацында** «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга;

**- 8 өлешнең унынчы абзацын** төшереп калдырырга;

**- 12 нче өлештә** «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;

**7. 37 статьяның 1 өлешендә,** «,ә ул булмаган очракта, Җирлек сайлау комиссиясе тарафыннан»;

**8. 38 статьяның 1 өлешендәге 13 пунктны** төшереп калдырырга;

**9. 46 статьяның 3 өлешендә** «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;

**10. 48 статьядагы 1 өлешнең икенче абзацында** «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;

**11. 49 статьяда:**
**- 4 өлешнең 2 пунктында а) пунктчасында** «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;
**- 4 өлешнең 2 пунктында б) пунктчасында :**
-«Татарстан Республикасы Президентын » сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;
- «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

**12. 52 статьяның 5 өлешендә** «Татарстан Республикасы Президентын » сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;

**13. 53 статьяда:**
**- 1 нче өлештә** «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;
**- 3 нче өлештә** «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга;
**- 4 нче өлештә** «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;
**- 5 нче өлештә** «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;
**- 6 нчы өлештә** «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;
**- 7 нче өлештә** «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;
**- 11 нче өлешнең 1 нче пунктында** «Татарстан Республикасы Президентын » сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;
**- 14 нче өлештә** «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисен» сүзләре белән алыштырырга;

**14. 56 статьяны 1 нче өлеше 5 нче пунктының бишенче абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чаралар оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнаша, җирлектә

яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыра һәм гамәлгә ашыра;";

**15. 58 статьяны** төшереп калдырырга;

**16. 65 статьяның 3 өлешендә** «һәм җирлекнең сайлау комиссиясе » сүзләрен төшереп калдырырга;

**17. 71статьяда:**
**- 1 өлешнең 1 пунктын** "федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш" дигән сүзләр белән тулыландырырга;
**- 1 өлешнең 2 пунктында** "яки белә торып дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматны бирү" сүзләрен ", федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, белә торып тулы булмаган мәгълүматны бирергә, яки белә торып дөрес булмаган мәгълүматны бирергә"дигән сүзләр белән алыштырырга;
**-2 нче өлешне** "федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш"дип тулыландырырга;

**18. 79 статьяны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
**"79 статья.** Муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү һәм аларның үз көченә керүе тәртибе.
1. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Урта Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге оештыручы булып торган оешмаларның хокукый статусын билгеләүче муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр рәсми рәвештә халыкка җиткерелгәннән соң үз көченә керә.
2. Муниципаль норматив хокукый актның, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүнең рәсми игълан ителүе булып аларның:
1) Тулы текстны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми рәвештә бастырып чыгару (https://pravo.tatarstan.ru; ЭЛ массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык no ФС77-60244 17.12.2013 элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор)тарафыннан бирелгән;
2) Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Урта Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру https://alekseevskiy.tatarstan.ru/alekseevskiy/lebedinskoe.htm;
3) адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру:
- ТР Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге Башкарма комитетының административ бинасы: Урта Тигәнәле авылы, Центральная урамы, 9 йорт;
- Урта Тигәнәле авылы, Совет урамы, 3 йорт мәгълүмат стенды;

- ТР Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлегенең Тиган-Буляк авыл мәдәният йорты бинасы: Тиган-Буляк авылы, Кирова урамы, 1йорт.

3. Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына гражданнарның керүен тәэмин итү өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташу пунктлары эшли.

адреслары буенча:

- ТР Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге Башкарма комитетының административ бинасы: Урта Тигәнәле авылы, Центральная урамы, 9 йорт;

4. Муниципаль норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, муниципаль хокукый актлардан яки Федераль закон белән чикләнгән мәгълүматлар булган аерым нигезләмәләрдән тыш, имзаланганнан соң 10 көн эчендә халыкка җиткерелә.

5. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Урта Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексына ярашлы рәвештә үз көченә керә.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр акт үзе башканы билгеләмәсә, имзаланган көннән үз көченә керә.

7. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә тиешле сайтларның домен исемнәре һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәү турындагы мәгълүматлар күрсәтелгән вакытлы матбугат басмалары, челтәр басмалары исемлеге, аларда муниципаль хокукый актлар, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр халыкка җиткерелә (рәсми бастырудан тыш), Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Урта Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән гомум мәгълүматка җиткерелә.».

**Урта Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы,** **И.К.Хәмәтвәлиев**
**Совет рәисе**

СОВЕТ СРЕДНЕТИГАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ